Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Мәмәтавыл Советы

КАРАРЫ

12 декабрь 2024 ел № 109

Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл Советының 2007 елның 30 январендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлегенең муниципальара хезмәттәшлектә катнашу тәртибе турында» карарының үз көчен югалтуын тану турында

Муниципаль хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Мәмәт авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл Советының 2007 елның 30 январендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлегенең муниципальара хезмәттәшлектә катнашу тәртибе турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Мәмәт авылы, Совет урамы,1 йорт, Чупай авылы, Совет урамы, 43А йорты, Сәмәрканд бистәсе Үзәк урамы, 1 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталына» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Мәмәт авыл
җирлеге башлыгы Х.М.Бәдгетдинова